**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КЕЧЕ БӨГЕЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТНЫҢ КЫРЫК ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 3**

Кече Бөгелмә авылы 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советының XXXXI сессиясенең №4 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп,

**Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советының XXXXI сессиясенең №4 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Халык алдында тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының « Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы («Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы инициативасы буенча

үткәрелүчесе («Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) – «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Кече Бөгелмә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Р.М. Йосыпов**